| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗЕЛЕНОДОЛЬСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|

| **ПОСТАНОВЛЕНИЕ** | Зеленодольск | **КАРАР** |
|---|---|---|
| 14.09.2023 | шәһәре | **№** 2798 |

Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 13 августындагы 1925 номерлы карары белән расланган, индивидуаль торак төзелеше объекты яки бакча йорты параметрларының планлаштырылган төзелеше турында хәбәрнамәдә күрсәтелгән параметрларның билгеләнгән параметрларга туры килүе һәм индивидуаль торак төзелеше объектын яки бакча йортын җир кишәрлегендә урнаштыруның рөхсәт ителүе турында хәбәрнамә җибәрү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2021 елның 30 декабрендәге 476-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 13 августындагы 1925 номерлы карары белән расланган, индивидуаль торак төзелеше объекты яки бакча йорты параметрларының планлаштырылган төзелеше турында хәбәрнамәдә күрсәтелгән параметрларның билгеләнгән параметрларга туры килүе һәм индивидуаль торак төзелеше объектын яки бакча йортын җир кишәрлегендә урнаштыруның рөхсәт ителүе турында хәбәрнамә җибәрү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына (алга таба - административ регламент) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Административ регламентның 2.5.1 пунктындагы беренче абзацында «индивидуаль торак төзелеше объектын төзү яки реконструкцияләү» дигән сүзләрне «индивидуаль торак төзелеше объектын төзү, реконструкцияләү » дигән сүзләр белән алыштырырга ("Күпфатирлы йортларны һәм күчемсез милекнең башка объектларын өлешле төзүдә катнашу турында һәм Россия Федерациясенең кайбер закон актларына үзгәрешләр кертү хакында" 2004 елның 30 декабрендәге 214-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә өлешле төзелештә катнашучыларның акчаларын җәлеп итеп, индивидуаль торак төзелеше объектларын төзүдән тыш)»

2. Әлеге карарны Зеленодольск муниципаль районы Советы Аппаратының җәмәгатьчелек һәм массакүләм мәгълүмат чаралары белән элемтә бүлегенә «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Зеленодольск муниципаль районы мәгълүмат сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) һәм Татарстан

Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru ) урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче вазыйфаларын башкаручы З.Ф. Хәбибуллин